# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**дүртенче чакырылышның кырык алтынчы утырышы**

**1 ноябрь 2024 ел** **№147** **Иске Җөри авылы**

Муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру планын формалаштыру һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне алуга дини оешманың хокукын нигезли торган документлар исемлеге һәм аларны бирү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 26 апрелендәге 325 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Кушымта итеп бирелгән, Муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру планын формалаштыру һәм бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мараков